КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

2020 елның 18 феврале, № 8-п

2020 елда «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре»
VII гомумроссия фотоконкурсын үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган “2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында боерык бирәм:

1. 2020 елның 1 апреленнән 1 сентябренә кадәр «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре»VII гомумроссия фотоконкурсын конкурсын оештырырга һәм үткәрергә.
2. «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» VII гомумроссия фотоконкурсы турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.
3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны җитәкче урынбасары И.Ф.Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче А.С.Сәлимгәрәев

1 нче кушымта

“Татмедиа” республика
матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
җитәкчесенең
2020 елның 18 февралендәге
8-п номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**“Россия халыкларының милли бәйрәмнәре”**
**VII гомумроссия фотоконкурсын үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. “Россия халыкларының милли бәйрәмнәре” VII гомумроссия фотоконкурсы (алга таба – Конкурс) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган “2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” дәүләт программасы нигезендә үткәрелә.

1.2. Конкурсның оештыручысы – “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Агентлык);

1.3. Конкурс турында Нигезләмә документлар кабул ителә башлауга кимендә 5 календарь көн кала Агентлыкның рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) “Яңалыклар”, “Конкурслар” бүлекләрендә урнаштырыла.

1.4. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар һәм акчалата бүләкләр тапшырыла;

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максаты – Россия халыкларының мәдәни мирасын саклап калуга һәм үстерүгә өлеш керткән аеруча мөһим һәм талантлы фотоэшләрне ачыклау;

2.2 Конкурсның бурычлары: тарихи мирасны, туган якның традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен сәнгати-эстетик кабул итүне тәрбияләү, тарихи һәм мәдәни мирасны, Россия халыклары гореф-гадәтләренең күптөрлелеген популярлаштыру.

## 3. Конкурста катнашучылар

3.1 Фотоконкурста конкурс өчен тәкъдим ителгән эшләрнең 18 яшькә җиткән авторлары һәм/яисә бу эшләргә хокукы булган затлар катнаша;

3.2. Конкурста Конкурс турында нигезләмәгә таянып, билгеләнгән вакытта гариза һәм эшләр тапшырган авторлар яисә авторлык коллективлары, ММЧ буларак теркәлгән редакцияләр (алга таба – ММЧ) катнаша;

3.3. Фотоконкурста катнашу авторның/авторлык коллективының яисә редакциянең эшләрне киләчәктә түләүсез нигездә, ләкин авторын/авторлык коллективын яисә редакциясен һәм хезмәттәшлек итү чыганагын күрсәтеп, файдалануга (мәгълүмати, фәнни, белем бирү яисә мәдәни максатларда, шул исәптән фоторәсемнәрне халыкка күрсәтү һәм бастырып чыгару) рөхсәт бирүен аңлата;

3.4. Өченче затлар авторлык хокукларын үтәмәгән өчен җаваплылык эшләрне тәкъдим иткән катнашучыларга йөкләнә;

3.5. Гариза бирүчеләр Конкурста катнашу өчен әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегендә бәян ителгән тәртиптә һәм анда күрсәтелгән шартларны, таләпләрне үтәп документлар әзерләргә һәм тапшырырга тиеш;

3.6. Гариза бирүче Конкурсның бер номинациясендә катнашу өчен бер генә гариза бирә ала;

3.7. Конкурска гариза бирүче берничә номинация буенча документлар тапшыра ала, бу очракта жюри тарафыннан карала торган документлар һәрбер номинация буенча аерым әзерләнергә тиеш.

## 4. Конкурсны үткәрү шартлары

4.1. Конкурска гаризалар кабул итү: 2020 елның 1 апреленнән.

Конкурска гаризалар кабул итү тәмамлану: 2020 елның 1 августы (әлеге датаны да кертеп)

Конкурсны оештыручының рәсми сайтында Конкурс йомгаклары турында мәгълүмат урныштыру: 2020 елның 1 сентябреннән дә соңга калмыйча.

Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү: мәгълүмат Конкурсны оештыручының рәсми сайтында «Конкурслар һәм проектлар» бүлегендә урныштырылачак.

4.2. Конкурста катнашу өчен түбәндәге документлар кабул ителә:

- әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә анкета-заявка, конкурс эшләренә аннотация белән;

- эшләр флешкартада тапшырыла, яисә “облако” виртуаль саклагычына актив сылтама бирелә;

- гамәлгә кую документлары (документларны сканер аша чыгарылган PDF-файл форматында тапшыру рөхсәт ителә):

1) юридик зат буларак теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН) (күчермәсе);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләп кую турында боерык (күчермәсе);

гамәлгә кую документлары (күчермәләре);

ММЧ теркәү турында таныклык (күчермәсе) – массакүләм мәгълүмат чаралары өчен;

2) юридик зат булмаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык (күчермәсе);

массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе уставы яисә, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясендә кимендә 10 кеше эшләсә, “Массакүләм мәгълүмат чаралары турында” 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – ММЧ турында Закон) 20 статьясы нигезендә аны алмаштыра торган шартнамә;

3) физик затлар (авторлар, авторлык коллективлары) өчен:

паспорт яисә аны алмаштыра торган документ (күчермәсе);

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә Персональ белешмәләрне эшкәртүгә, таратуга һәм тапшыруга ризалык бирү;

4) уртак эшләрне тәкъдим итә торган ММЧ редакцияләре өчен:

конкурс эшенә призлы урын бирелгән очракта акчаны процентлап бүлешү турында килешү.

4.3. Конкурска килгән эшләргә рецензия бирелми

Катнашу өчен бирелгән заявка эшләрне конкурсантлар исемлегенә кертү өчен нигез булып тора. “Россия халыкларының милли бәйрәмнәре” конкурсында катнашу өчен анкета-заявка tatmedia.tatarstan.ru порталында “Конкурслар һәм проектлар” бүлегендә урнаштырылган;

4.4. “Россия халыкларының милли бәйрәмнәре” конкурсында катнашу өчен анкета-гариза, фотоэшләр бу хакта мәгълүмат урнаштырылган көннән алып 2020 елның 1 сентябренә кадәр Конкурсның оештыру комитетына электрон почта аша foto-konkurs2019@mail.ru адресына яисә “Россия халыкларының милли бәйрәмнәре” конкурсына билгесе белән “Татмедиа” матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына (420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, ММЧ бүлеге, 608 нче кабинет) җибәрелә.

Тел/факс: (843) 570-31-12;

4.5. Конкурска җибәрелгән, ләкин күрсәтелгән датага алынмаган эшләр, Нигезләмәнең 4.13 пункты нигезендә, кабул ителмичә авторларына кире кайтарыла;

4.6. Анкета-гаризаны һәм конкурс эшен билгеләнгән срокны бозып тапшыру, анкета-гаризаның/конкурс эшенең булмавы, анкета-гаризаның/конкурс эшенең әлеге Нигезләмәгә туры килмәве, сурәтендә хилафлыклар булган эшләрне тәкъдим итү Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигез булып тора;

4.7. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һ.б.) катнашучы тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

4.8. Конкурска коллажлар, язулары, даталары булган фотоэшләр, кысалар һәм почмаклар өстәлгән фотоэшләр, шулай ук фотомонтаж һәм компьютер ярдәмендә үзгәртелгән фотоэшләр кабул ителми.

4.9. Тәкъдим ителгән эшләр 2019 елның 1 ноябреннән дә иртәрәк төшерелгән булырга тиеш түгел.

4.10. Фотографияләр jpeg форматында, кадрның иң зур ягы кимендә 4000 пиксель, максималь сакланган (кысылмаган) булырга тиеш;

4.11. Конкурска йомгак 2020 елның 1 сентябреннән дә соңга калмыйча ясала, беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә һәм рәис тарафыннан имзалана.

4.12. Конкурс шартлары буенча, тәкъдим ителгән эшләрне катнашучыларга кире кайтару, конкурста катнашучының эшне кире кайтару турындагы таләбе буенча гына, мондый таләп алынган мизгелдән алып 20 (егерме) календарь көн дәвамында гамәлгә ашырыла;

4.13. Катнашучыга Конкурска кертелмәү турында хәбәр документларны алган мизгелдән алып 5 эш көне дәвамында Оештыручы җитәкчесе/җитәкче урынбасары имзалаган һәм анкета-гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы рәсми хат белән хәбәр ителә.

## 5. Конкурсның номинацияләре

5.1. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

- “Иң яхшы фото” (әлеге номинациягә бер генә фотография тапшырырга мөмкин);
- “Фотоэшләр сериясе”. Әлеге номинация конкурс максатларына туры килә торган фотоэшләрдән җыелманы күздә тота (кимендә 3 һәм иң күбе 6 фоторәсем);
- “Портрет” (әлеге номинациягә бер генә фотография тапшырырга мөмкин).

## 6. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

6.1. Конкурс эшләрен бәяләгәндә түбәндәге критерийлар исәпкә алына:
- Конкурс тематикасын чагылдыра торган эчтәлек (0-5 балл);
- эшнең кабатланмаган һәм оригиналь булуы (0-5 балл);
- үтәлеш сыйфаты (0-5 балл);
- эшкә иҗади якын килү (0-5 балл);
- темага туры килү (0-5 балл).

6.2. Балларның гомуми суммасыннан чыгып, призлы урыннар билгеләү:

1 урын: 25-20 балл

2 урын: 19-15 балл

3 урын: 14-10 балл.

## 7. Оештыру комитетын конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе

7.1 Оештыру комитетының һәм конкурс комиссиясенең составы Конкурсны оештыручы боерыгы белән 8 кеше составында раслана һәм комиссия рәисеннән, комиссия әгъзаларыннан тора;

7.2. Оештыру комитеты мәдәният һәм сәнгать өлкәсе белгечләреннән, Татарстан Республикасы Фотографлар берлеге вәкилләреннән төзелә;

7.3. Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне башкара: тәкъдим ителгән эшләрнең номинациягә туры килүен тикшерә, эшләрне төшереп калдыру 4.9 пункт нигезендә башкарыла.

7.4. Конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы мәдәният һәм сәнгать өлкәсе белгечләреннән, иҗтимагый оешмалары вәкилләреннән төзелә;

7.5. Конкурс комиссиясенең эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Утырышта комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип таныла.

7.6. Конкурс эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары аның тарафыннан билгеләнгән урынбасарына йөкләнә.

7.7. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурска тапшырылган эшләрне әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары буенча бәяли. Һәрбер критерий буенча балларның саны 5 баллы шкала (0 – 5 балл) буенча бәйләнә. Конкурс эше дөрес номинациягә тапшырылмаган булса, ул “0” балл белән бәяләнә;

7.8. Бер номинациягә бер генә гариза тапшырылса, бер гариза да тапшырылмаса, тапшырылган гаризаларның берсе дә конкурс шартларына

туры килмәсә, катнашкан эшләрнең берсе дә билгеләп үтәргә лаек дип танылмаса, Конкурс бу номинациядә үткәрелмәгән дип танылa һәм акчалар билгеләнгән башка җиңүчеләр арасында тигез итеп бүленә.

7.9. Номинациядә тигез баллар җыелган очракта Конкурс комиссиясе призлы урынны  ике яки берничә катнашучыга бирә, мондый очракта призлы урын өчен тәгаенләнгән акчалар җиңүчеләр арасында тигез өлешләрдә бүленә.

7.10. Җиңгән эш берничә авторныкы (физик затлар өчен)/берничә ММЧ (юридик затлар өчен) булса, номинациянең әлеге урыны өчен тәгаенләнгән акчалар җиңүчеләр арасында әлеге Нигезләмәнең 4.1 пункты нигезендә документлар белән бергә тапшырыла торган килешү нигезендә тигез өлешләп бүленә.

7.11. Конкурсны комиссиясе составы рәисе оештыру-техник эшчәнлекне җайга салу, утырышны әзерләү һәм конкурс комиссиясе документациясен алып бару өчен җаваплы секретарь билгеләп куя.

7.12 . Җаваплы секретарь түбәндәгеләрне башкара:

- материалларны конкурс комиссиясе тарафыннан карауга әзерли һәм аларның сакланышын тәэмин итә;
- конкурс комиссиясе әгъзалары белән элемтәдә тора;
- конкурс комиссиясе утырышларын әзерли;
- конкурс комиссиясе беркетмәләрен рәсмиләштерә;

7.13. Җаваплы секретарь конкурс комиссиясе составына керми һәм утырышларда тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

## 8. Финанс белән тәэмин итү

8.1. Конкурсны үткәрү чаралары Татарстан Республикасы бюджетыннан “2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән финанслана;

8.2. Гомуми приз фонды 225 000 сум тәшкил итә;

8.3. Әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән номинацияләр буенча Конкурста җиңүчеләр  I, II һәм III дәрәҗә дипломнар белән бүләкләнә.

8.4. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

**“Иң яхшы фото”** номинациясендә җиңүчеләргә:

1 урын – I дәрәҗә диплом һәм 30 000 сум приз;

2 урын – II дәрәҗә диплом һәм 22 000 сум приз;

3 урын – III дәрәҗә диплом һәм 15 000 сум приз.

**“Фотоэшләр сериясе”** номинациясендә җиңүчеләргә:

1 урын – I дәрәҗә диплом һәм 40 000 сум приз;

2 урын – II дәрәҗә диплом һәм 30 000 сум приз;

3 урын – III дәрәҗә диплом һәм 20 000 сум приз.

**“Портрет”** номинациясендә җиңүчеләргә:

1 урын – I дәрәҗә диплом һәм 35 000 сум приз;

2 урын – II дәрәҗә диплом һәм 25 000 сум приз;

3 урын – III дәрәҗә диплом һәм 15 000 сум приз.

8.5. Юридик һәм физик затларга призлар Конкурс йомгаклары турында беркетмәгә имза салынган мизгелдән алып 20 көн дәвамында аларның исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә, реквизитлар Оештыручыга язылган хатта күрсәтелә.

8.6. Җиңүчеләрне бүләкләү датасы һәм урыны өстәмә рәвештә хәбәр ителәчәк.

## 9. Аерым шартлар

9.1.Оештыручылар түбәндәгеләргә хокуклы:

- әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән очраклардан, шулай ук бәхәсле очраклардан тыш, Конкурста катнашучылар белән язмача йә башка төрле элемтәләргә кермәскә;
- эшләрне тапшыру срогының беренче яртысында Россия Федерациясе законнары таләпләрен (РФ ГК 1058 ст.) үтәп, Конкурсны туктатырга яки әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, бу хакта Агентлыкның рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) “Яңалыклар” бүлегендә һәм Министрлыкның рәсми сайтында (http://mvd.tatarstan.ru) “Яңалыклар” бүлегендә тиешле мәгълүмат урнаштырып, Катнашучыларга хәбәр итәргә.

9.2. Конкурсның максатларын һәм бурычларын үзгәртүдән тыш, калган барлык шартларына үзгәрешләр кертергә мөмкин.

“Россия халыкларының милли бәйрәмнәре” VII гомумроссия фотоконкурсын үткәрү турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

“Россия халыкларының милли бәйрәмнәре”
VII гомумроссия фотоконкурсында катнашу өчен
АНКЕТА-ГАРИЗА

**Автор (иҗат коллективы)**

______________________________________________________________

**Номинация исеме:**

______________________________________________________________

**Конкурска җибәрелгән эшнең исеме**

______________________________________________________________

**Кыскача эчтәлеге**

______________________________________________________________

**Телефон /факс:**

______________________________________________________________

**Электрон адрес:**

______________________________________________________________

**Адрес:**

______________________________________________________________

**ФОТОЭШКӘ ХОКУКЫ БУЛГАН ЗАТНЫҢ РИЗАЛЫГЫ**

- Фотоэшне яисә аның фрагментларын киләчәктә файдалану, шул исәптән мәгълүмат бирү, фәнни, белем бирү яисә мәдәни максатларда түләүсез халыкка күрсәтү һәм фотографияне бастырып чыгару максатларында файдалану хокукын тапшыруга РИЗАЛЫГЫМНЫ БИРӘМ;

______________________________________________________________________________________________________________________________

(ФИАт. ис, имза)

Конкурс эшләре һәм әлеге гаризаның төп нөсхәсе Конкурсның оештыру комитеты тарафыннан агымдагы елның 1 августыннан дә соңга калмыйча алынырга тиеш. Эшләрне «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» фотоконкурсына» дип язып, түбәндәге адреска җибәрергә кирәк:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2
“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы
Тел/факс: (843)570-31-12
E-mail: foto-konkurs2020@mail.ru
«Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» фотоконкурсын оештыру комитеты

“Россия халыкларының милли бәйрәмнәре” VII гомумроссия фотоконкурсын үткәрү турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,____________________________________________________________
___, яшәү адресым_______________________________________________
_____________________________________________________________________
__, шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)______________________
_____________________________________________________________________
_________________________________________, “Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420097, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) “Россия халыкларының милли бәйрәмнәре” VII гомумроссия фотоконкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.
Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге: | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр) |

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.
Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор

йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

________________________________________________________________/______________

(персональ белешмәләр субъектының Ф.И.Ат ис. һәм имзасы)

_______________
(Дата)